ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07. 10. 2019 г.Мензелинск № 928

Минзәлә муниципаль районы территориясендә даими хәзерлектәге эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд булдыру турында

Россия Федерациясенең 14.05.1993 елдагы “Ветеринария турында”гы № 4979-1 Законы, 30.03.1999 елдагы “Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында”гы №52-ФЗ Федераль законы нигезендә, кеше һәм хайваннар өчен гомуми булган аеруча куркыныч авырулар чыганаклары белән көрәш һәм профилактикалау максатларында, Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Минзәлә муниципаль районы территориясендә даими хәзерлектәге эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд булдырырга.

2. Расларга:

1 нче Кушымта нигезендә Минзәлә муниципаль районы территориясендә даими хәзерлектәге эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд турында (алга таба – Отряд) Нигезләмә;

2 нче кушымта нигезендә Отрядның оештыру-штат структурасын;

3 нче кушымта нигезендә Отрядның исәп составын;

4 нче кушымта нигезендә Отряд составына кертелгән автомобиль техникасы исемлеген;

5 нче кушымта нигезендә эш вакытында һәм эш вакыты булмаганда Отряд төркеме командирларына хәбәр җиткерү схемасын;

6 нчы кушымта нигезендә Отряд төркемнәренең командирларына хәбәр җиткерү һәм җыю буенча кизү торучы район дәүләт ветеринария берләшмәсенең инструкциясен.

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Минзәлә муниципаль районы буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигына йөкләргә.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев.

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
Кушымта №1
дата 07.10 2019 № 928

Минзәлә муниципаль районы территориясендә даими хәзерлектәге эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отряд булдыру турында
Нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Гамәлдәге нигезләмә Минзәлә муниципаль районы территориясендә даими хәзерлектәге эпизоотиягә каршы җыелма мобиль отрядының (алга таба – Отряд) функцияләшүе һәм оештыру тәртибен билгели.

1.2. Отряд штаттан тыш формирование булып тора һәм Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән Минзәлә муниципаль районында сәбәбе хайваннардагы аеруча куркыныч авырулар булган, социаль биологик характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан һәм килеп чыгу куркынычы туу куркынычы белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән һәм кеше һәм хайваннар өчен гомуми булган аеруча куркыныч авырулар чыганаклары белән көрәш һәм профилактикалау максатларында булдырыла.

1.3. Отряд үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясен һәм Татарстан Республикасы Конституциясен, Россия Федерациясенең 14.05.1993 елдагы “Ветеринария турында”гы Законын, Россия Федерациясенең 30.03.1999 елдагы “Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында”гы №52-ФЗ Федераль законын, Россия Федерациясенең 04.12.1995 елдагы №13-7-2/469 Баш дәүләт ветеринария инспекторы белән расланган Биологик калдыкларны җыю, утильләштерү һәм юк итү ветеринария-санитария кагыйдәләрен, кеше һәм хайваннар өчен гомуми булган куркыныч авырулар чыганакларын профилактикалау һәм ликвидацияләү мәсьәләләре буенча кешенең иминлеген һәм кулланучыларның хокукларын яклау өлкәсенә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәтнең башка норматив-хокукый актларын, Минзәлә муниципаль районы башлыгының боерыкларын һәм күрсәтмәләрен, Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының боерыкларын һәм күрсәтмәләрен, шулай ук гамәлдәге Нигезләмәне кулланып эш итә.

1.4. Отряд “Минзәлә район дәләт ветеринария берләшмәсе” ДБУ, Россия ЭЭМнең Минзәлә районы буенча бүлеге белән килешенеп белгечләр арасыннан, шулай ук “Минзәлә район үзәк хастаханәсе” ДАССИ, “Минзәлә районы Коммуналь челтәрләр” АҖ, Яр Чаллыда, Актаныш районында “Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБССИ филиалы һәм җирле үзидарә органнары вәкилләре һәм белгечләре арасыннан формалаша.

1.5. Отрядның шәхси составы тиешле профилактив вакцинацияне үзвакытында узарга тиеш.

## 2. ОТРЯДНЫҢ БУРЫЧЛАРЫ

2.1. Отряд сәбәбе хайваннардагы аеруча куркыныч авырулар булган, социаль биологик характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан һәм килеп чыгу куркынычы туу куркынычы белән бәйле мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән һәм кеше һәм хайваннар өчен гомуми булган аеруча куркыныч авырулар чыганаклары белән көрәш һәм профилактикалау максатларында, вәзгыятьне контрольдә тоту максатларында булдырыла.

2.2. Отрядның бурычлары этаплап билгеләнә:

беренче этап – авыруны китереп чыгару төрен билгеләгәнгә кадәр (яисә авыру сәбәпләрен һәм хайваннарның үлүе сәбәпләрен);

икенче этап – авыру китереп чыгаручы төре билгеле булгач һәм төгәл диагноз куйгач.

2.2.1. Беренче этапта Отрядның бурычлары:

– ветеринария һәм медицина күзәтүен гамәлгә ашыру;

– эпидемиологик һәм эпизоотик вәзгыятькә бәя бирү;

– контактта булган, зәгыйфьләнгән һәм авыру хайваннарны аерып алу (алга таба – авыру хайваннар);

– үлгән, клиник авыру хайваннардан патологик материалны сайлап алу;

– вируслы тикшеренү һәм дифференцияле диагностика уздыру өчен махсуслашкан лабораторияләргә пробаларны илтү;

– хайваннарны читләштергәннән соң җиһазларга, инвентарьгә һәм бинага агымдагы һәм соңгы тапкыр дезинфекцияләү уздыру;

– бинага һәм территорияләргә механик чистарту уздыру.

2.2.2. Икенче этапта Отрядның бурычлары:

– карантин зонасында үткәрү режимына тәүлек әйләнәсе контрольне гамәлгә ашыру;

– карантин зонасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү;

– карантин зонасында булган халык арасында профилактик һәм эпидемиягә каршы чаралар уздыру;

–эпизоотик чыганакта барлык авыру хайваннарны аулау һәм чалу;

– үтерелгән хайваннарны транспортировкалау һәм аларны утильләштерү урыннарына чыгару (юк итү);

– үтерелгән хайваннарның мәетләрен утильләштерү;

– Отрядның шәхси составын һәм эпизоотик чыганакны ликвидацияләүдә катнашучы башка затларны санитар эшкәртү;

– бер тапкыр кулланыла торган саклану чараларын юк итү;

– дезинфекция буенча чараларның барлык комплексын уздыру;

– хайваннарның аеруча куркыныч авыруларын ликвидацияләү максатларында уздырыла торган чараларның зарурылыгы һәм максатчанлыгы турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка мәгълүмат бирү.

## 2. ОЕШТЫРУ СТРУКТУРАСЫ, ОТРЯД ПОДРАЗДЕЛЕНИЕЛӘРЕНЕҢ ҖИҺАЗЛАНЫШЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

3.1. Отряд командиры һәм шәхси состав Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә. “Минзәлә районы дәүләт ветеринария берләшмәсе” ДБУ начальнигы Отряд командиры булып тора.

3.2. Отряд төп подразделениеләрдән һәм тәэмин итү подразделениеләреннән тора.

Төп подразделениеләр:

– ветеринар разведка төркеме;
– хайваннарны аулау һәм йоклату төркеме;
– утильләштерү төркеме;
– дезинфекция төркеме.

Тәэмин итү подразделениеләре:

–медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме;
– үткәрү режимын тәэмин итү төркеме;
– җәмәгать тәртибен саклау төркеме;
– табиб-медицина бригадасы;
– янгын подразделениесе;
–санитар эшкәртү пункты.

3.3. Ветеринар разведка төркеме үлгән (авыру) хайваннар ачыкланган (табылган) урынга чыгуны, патологик материалны сайлауны (кан сүле пробасын, патологик материалны һәм биоматериалны сайлау тәртибе буенча Инструкция нигезендә), аларны махсуслашкан лабораториягә илтүне (тикшеренү өчен пробаларны китерү тәртибе нигезендә) һәм үлгән (авыру) хайваннар ачыкланган (табылган) урын янәшәсендәге территорияләрне һәм күрше ишегалларын йөреп чыгуны гамәлгә ашыра, үлгән хайваннарның учетын алып бара.

Ветеринар разведка төркеме даими әзерлек режимында тора һәм хайваннарның үлү (авыру) очраклары турында мәгълүмат алганнан соң бер сәгать эчендә урынга чыга.

Ветеринар разведка төркеме район дәүләт ветеринария берләшмәсе хезмәткәрләре арасыннан формалаша. Ветеринар разведка командиры Отряд командиры урынбасары булып тора.

Ветеринар разведка төркеменең шәхси составы шәхси саклану костюмнары. Сулыш органнарын саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемнең җиһазланышы: авыру хайваннарны аулау өчен инвентарь, патологик материал алу өчен махсус инструментлар, патологик материалны транспортировкалау өчен хладагентлы термоконтейнер, патологик материалны лабораториягә җибәрү бланклары, мобиль элемтә чаралары, полиэтилен капчыклар, дезинфиция чаралары, кулларны юу өчен сулы савыт (кимендә 5 литрлы), сөлге, сабын, бинокль, фонарь, үлгән хайваннарны теркәү журналы.

3.4. Хайваннарны аулау һәм йоклату төркеме авыру хайваннарны аулауны гамәлгә ашыра, хайваннарны кан чыгармыйча йоклату, аларны җыю һәм транспортка төяү буенча чаралар уздыра , үтерелгән хайваннарның исәбен алып бара.

Хайваннарны аулау һәм йоклату төркеме районның ветеринария берләшмәсе, җирле үзидарә органнары, финанс органы хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Төркемнең шәхси составы шәхси саклану костюмнары һәм сулыш органнарын саклау чаралары белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазландыру: хайваннарны тотып алу өчен инвентарь, полиэтилен капчыклар, хайваннарны йоклату чаралары, автомат шприцлар, үтерелгән хайваннарны теркәү журналы һәм дезинфекция чаралары.

3.5. Утильләштерү төркеме утильләштерү урынын әзерли, утильләштерү урынында хайван мәетләрен бушатуны гамәлгә ашыра, дезинфекцияләүче чаралар кулланып биотермик чокырларда хайван мәетләрен утильләштерүне яисә шәхси куркынычсызлык һәм янгынга каршы чараларны катгый үтәп, яндыру юлы белән мәетләрне утильләштерүне уздыра, утильләштерелгән хайван мәетләренең исәбен алып бара.

Утильләштерү төркеме район дәүләт ветеринария берләшмәсе, “Чиста шәһәр” МУП, җирле үзидарә органнары вәкилләре арасыннан формалаша.

Утильләштерү төркеме составындагы ветеринария-санитар экспертиза лабораториясенең ветеринария табибы чаласы хайваннарны ветеринар тикшерү һәм ит һәм ит продукцияләренә ветеринария-санитар экспертиза Кагыйдәләре нигезендә чалынган продуктка ветеринария-санитар бәя бирүне уздыра

Төркемнең шәхси составы саклагыч костюмнар, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазландыру: экскаватор һәм металл кузовлы йөк автомобиле (яисә металл сыйдыргыч белән җиһазланган автомобиль), дезинфекция чаралары, утильләштерелгән хайваннарны учетка алу журналы.

3.6. Дезинфекция авыру хайваннар ачыкланган урында механик чистарту, инфекция чыганагына агымдагы һәм соңгы дезинфекция уздыра (ветеринар дезинфекция, дезинвазия, дезинсекция һәм дератизация уздыру буенча Инструкция нигезендә). Дезинфекция төркеме “Минзәлә район дәүләт ветеринария берләшмәсе” ДБУ хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Төркемнең шәхси составы саклагыч костюмнар, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазландыру: Комаров дезинфекция җайланмасы һәм дезинфекция чаралары.

3.7. Медицина һәм эпидемиология төркеме түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

– медицина һәм санитария-эпидемиология разведкасын башкару һәм эпидемия чыганагына күзәтчелек итү;

– чыганакта яшәүче халыкка һәм куркыныч булырдай төркем затларына медицина тикшерүе уздыру (Отрядның һәм эпизоотия чыганагын ликвидацияләүче башка катнашучыларның шәхси составы);

– авыруларны ачыклау (авыру шиге булганда) максатыннан һәр ишегалдын йөреп чыгу һәм авырулар белән аралашучыларны һәм контакт дәрәҗәсен билгеләү;

– республиканың махсуслашкан лабораторияләренә лаборатор тикшеренү өчен материалны сайлау һәм илтү;

– экстрен профилактика һәм экстрен профилактиканы оештыру һәм уздыруга контроль;

– авыруларны, авыру шиге туган затларны вакытлыча изоляцияләү;

– эпидемик чыганакта агымдагы һәм ахыргы дезинфекция уздыру һәм контроль;

– Отряд командирына разведка мәгълүматларын тапшыру.

Медицина һәм эпидемиологик разведка төркеме “Минзәлә район үзәк хастаханәсе” ДАССУ һәм “Татарстан Республикасының (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге” ФБССИ Яр Чаллы шәһәрендәге һәм Актаныш районындагы филиалы хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Медицина һәм эпидемиологик разведка төркеменең шәхси составы саклагыч костюмнар, сулыш органнарын саклау чаралары, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

Төркемне җиһазландыру : лаборатор тикшеренүләр өчен материалны сайлау өчен салып кую, табибның салып куюы.

3.8. Үткәрү режимын тәэмин итүче карантин зонасында хәрәкәтне җайга салуны оештыра һәм тәэмин итә. Төркем контроль-пост хезмәтеннән һәм контроль-үткәрү постыннан тора. Постлар саны карантин зонасына керү (чыгу) саны белән билгеләнә.

Торак пунктка төп керү (чыгу) урыннарында (карантин зонасына) контроль-үткәрү постлары, иярченнәрендә – патруль-пост хезмәте постлары булдырыла. Үткәрү режимын тәэмин итүче төркем Россия Эчке эшләр министрлыгының Минзәлә районы буенча бүлеге, Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе һәм “Минзәлә район дәүләт ветеринария берләшмәсе” ДБУ хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Контроль-үткәрү постын җиһазландыру: җиңел автомобиль, мобиль элемтә чаралары, дезинфекция барьеры, шлагбаум, халыкның чишенү-киенү урыны, Комаров дезинфекция җайланмасы яисә транспорт чараларын юу һәм дезинфекцияләү өчен транспорт чаралары һәм транспорт чараларын дезинфекцияләү, эшкә эремә әзерләү өчен савыт, су савыты, дезинфекция чаралары, юынгыч, сөлге, сабын, "Карантин" язуы белән алтакта.

Патруль-пост хезмәте постын җиһазландыру: җиңел автомобиль, мобиль элемтә чаралары, шлагбаум, "Карантин" язуы белән алтакта, карантин зонасына урап керүне күрсәтүче юл билгеләре, фонарь.

Үткәрү режимы төркеменең шәхси составы саклагыч костюмнар, сулыш органнарын саклау чаралары, итекләр, резина перчаткалар белән тәэмин ителә.

3.9. Җәмәгатьчелек тәртибен саклаучы төркем карантин зонасында хокук тәртибе саклануын тәэмин итә, Отрядның шәхси составын, иң беренче чиратта, хайваннарны аулау һәм йоклату төркемен һәм медицина һәм эпидемиология разведкасы төркемен озатып йөрүне һәм саклауны оештыра.

Җәмәгатьчелек тәртибен саклау төркеме Россия Эчке эшләр министрлыгының Минзәлә районы буенча бүлеге хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Төркемнең шәхси составы кораллану һәм саклануның штаттагы чаралары белән тәэмин ителә һәи җиһазландырыла.

3.10. Табиб-шәфкать туташы бригадасы карантин-чикләү чараларын уздыру чорында халыкка кичектергесез медицина ярдәме күрсәтә, ачыкланган авыруларны инфекция бүлегенә яткыруны оештыра.

Табиб-шәфкать туташы бригадасы “Минзәлә район үзәк хастаханәсе” ДАССИ хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Бригаданың шәхси составы саклагыч костюмнар, халатлар, баш киемнәре һәм битлекләр белән тәэмин ителә.

Бригадагы җиһазландыру: Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының җитәкчелек документлары таләпләре нигезендә табиб салуы һәм табель милке.

3.11. Янгын сүндерү расчёты үтерелгән хайваннарны яндырганда янгынга каршы куркынычсызлык чаралары үтәлешен гамәлгә ашыра.

Минзәлә муниципаль районының ирекле янгын сүндерү командасының машина йөртүче-янгын сүндерүчесе яндыру урынын сайлаганда катнаша. Янгын килеп чыкканда сүндерүне оештыра һәм уздыра.

3.12. Санитар-эшкәртү пункты шәхси составка һәм транспорт чараларына санитар эшкәртү һәм бер тапкыр кулланыла торган киемнәрне яндыру юлы белән юк итүне уздыра.

Санитар-эшкәртү пунктының шәхси составы шәхси составка һәм транспорт чараларына санитар эшкәртү уздыра һәм "Минзәлә районы Коммунал челтәрләр" АҖ хезмәткәрләре арасыннан формалаша.

Кешеләр һәм хайваннар авырулары чыганагын локальләштерү һәм ликвидацияләү буенча чаралар комплексы тәмамланганнан соң, карантин зонасында эшкә җәлеп ителгән затлар һәм Отрядның шәхси составы мәҗбүри санитар эшкәртү узалар, ә бер тапкыр кулланыла торган махсус киемнәр яндыру юлы белән юк ителәләр.

Пунктны җиһазландыру: Комаров дезинфеция җайланмасы (күчмә душ җайланмалары яисә ранецлы дезинфекция сиптергечләре), су савыты, сабын, сөлге, утын.

## 3. ОТРЯД КОМАНДИРЫ БУРЫЧЛАРЫ

4.1. Отряд командиры эпидемия чыганагында эпизоотиягә каршы чараларны оештыру һәм уздыру һәм Отрядны шәхси состав һәм мөлкәт белән тәэмин итү өчен җавап бирә һәм хайваннарның йогышлы авырулары чыганагын ликвидацияләү буенча бурычларын үтәү чорына Отрядның бөтен шәхси составының турыдан-туры начальнигы булып тора.

4.2. Отряд командиры бурычлы:

- чыганакта эпизоотиягә каршы чараларны оештыру һәм алып бару буенча җитәкчелек документлары таләпләрен белергә һәм үз эшчәнлеге өре буенча аларны кулланырга;

– Отряд гамәлдә булган һәм урнашкан районда ветеринария-санитария һәм эпизоотия торышын өйрәнергә;

– эшне камилләштерү һәм Отрядның чыганактагы гамәлләренә әзерлеген күтәрү буенча чараларны оештырырга һәм эшкәртергә;

– хайваннарның йогышлы авырулары белән эпизоотия торышы буенча, әлеге авырулар белән көрәш чаралары, зарарланган һәм зарарлануы шикле хайваннар белән эшләрдә техник куркынычсызлык кагыйдәләре турында ветеринария хезмәте белгечләренә мәгълүмат бирүне оештыру;

– карантин салыну турында – Минзәлә муниципаль районының Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын курнкынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе карарын эшләү буенча тәкъдимнәр кертергә;

– шәхси составның махсус әзерлеген оештыру һәм уздыру;

– Отряд подразделениеләренең ихтыяҗын билгеләргә һәм белергә;

– отряд өчен тиешле булган матди һәм дезинфекция чараларын үзвакытында таләп итү һәм алу;

– матди чараларның исәбен, сакланышын һәм файдаланышын контрольдә тоту;

– Отрядның шәхси составы белән аны эпизоотия чыганагындагы гамәлләргә әзерлеккә китерү буенча тренировкалар уздырырга;

– Минзәлә муниципаль районының Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисенә гадәттән тыш хәлләрне ликвидацияләү зонасында эпизоотия торышы турында мәгълүматларны үзвакытында тапшырырга;

– Отрядның шәхси составының функциональ бурычларын эшкәртүдә катнашырга һәм аларны расларга;

– Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә карантинны туктату буенча тәкъдимнәр кертергә.

## 4. ОТРЯДНЫ ӘЗЕРЛЕККӘ КИТЕРҮ ТӘРТИБЕ

5.1. Сигнал алынган мизгелдән Отрядны әзерлеккә китерүгә гомуми вакыт – 2 сәгатьтән артмый. Шул ук вакытта ветеринария разведкасы төркеме бер сәгать эчендә эпизоотия чыганагына якынлаша.

5.2. Шәхси составка хәбәр итүне һәм җыюны, комплектлауны, эпизоотия чыганагына җыену һәм чыгу чорында Отряд белән идарә итүне кертеп, Отрядны әзерлеккә китерү буенча барлык чаралар Отряд командиры карары буенча гамәлгә ашырыла.

5.3. Отрядның шәхси составына хәбәр итү һәм җыю өчен “Минзәлә район дәүләт ветеринария берләшмәсе” ДБУнең кизү торучысына Инструкция эшләнә.

5.4. Подразделение командирлары җыену урынына килү белән, шәхси составның, автомобиль техникасының һәм шәхси составның бурычларны үтәргә әзерлеге турында Отряд командирларына хәбәр итәләр.

## 6. ОТРЯДНЫҢ ШӘХСИ СОСТАВЫН ӘЗЕРЛӘҮ

6.1. Отрядка кертелгән белгечләрнең штат вазыйфасы буенча эш тәҗрибәсе булырга тиеш.

6.2. Методик-инструкторлык дәресләре, практик тренировкалар һәм өйрәнүләр Отрядның шәхси составын әзерләүнең төп ысуллары булып тора.

Шәхси состав белән методик-инструкторлык дәресләрендә төп игътибар куркынычсызлык чараларын үтәү, эпизоотия чыганагында эшләгәндә шәхси составның инфекцияле авыруларын кисәтү мәсьәләләренә, шәхси саклану чараларыннан файдаланганда кагыйдәләргә, шулай ук кеше һәм хайваннар өчен гомуми булган аеруча куркыныч авырулар белән көрәш буенча чаралар турындагы инструкция таләпләрен җиткерүгә, һәм гамәлдәге Нигезләмәгә бирелә.

Отрядның шәхси составы белән методик-инструкторлык дәресләрен подразделение командирлары уздыра.

Тренировкаларны әзерләү, уздыру һәм тикшерү өчен Отряд командиры җавап бирә.

## 7. ОТРЯДНЫҢ ДОКУМЕНТЛАР ИСЕМЛЕГЕ

7.1. Отрядта документларның мәҗбүри исемлеге формалаша. Документларның бер экземпляры Минзәлә муниципаль районының Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын саклау комитеты рәисендә, икенчесе – Отряд командирында була.

7.2. Отрядның документациясен алып бару, дөрес итеп рәсмиләштерү һәм документлардагы мәгълүматларны үзвакытында аныклау өчен Отряд командиры җавап бирә.

7.3. Отряд документлары исемлеге:

– Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының даими әзерлектәге эпизоотиягә каршы берләштерелгән мобиль отрядын булдыру һәм комплектлау турындагы карарның күчермәсе;

– Отрядның оештыру-штат структурасы;

– Отрядның исәп составы;

– Отряд составына кертелә торган автомобиль техникасының исемлеге;

– эш вакытында һәм эш вакыты булмаганда Отряд төркеме командирларына хәбәр итү схемасы;

– Отрядның шәхси составына хәбәр итү һәм җыю буенча район дәүләт ветеринария берләшмәсенең кизү тору инструкциясе.

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль районы
Башкарма комитетының карарына
Кушымта №2

дата __________ 20___ №______

## Отрядның оештыру-штат структурасы

**Командир (РГВО җитәкчесе)** – 1 кеше.
җиңел автомобиль – 1 берәмл.

**Шәхси состав – 47 кеше.**
**техника – 17 берәмл.**

**Ветеринария разведкасы төркеме** (л/с 3 кеше., 1 берәмл. техника):
– командир (РГВО җитәкчесе урынбасары) – 1 кеше.
– лаборант (РГВО) – 1кеше.
– водитель (РГВО) – 1 кеше.

**Хайваннарны тотып алу һәм йоклату төркеме**
(ш/с 5 кеше., 1 берәмл. техника):
- төркем командиры (баш табиб-эпизоотолог РГВО) – 1 кеше.
– хайваннары тотучы (РГВО) – 3 кеше.
– учётчы (РГВО) – 1 кеше.
җиңел автомобиль (РГВО) - 1 берәмл.

**Утильләштерү төркеме** (ш/с 8 кеше., 3 берәмл. техника):
– төркем командиры (МУП «Чиста шәһәр») – 1 кеше.
– утильләштерүче (МУП «Чиста шәһәр») – 3 кеше.
– учётчы (РГВО) – 1 кеше.
– ветеринария-санитария эксперты (РГВО) – 1 кеше.
– йөк автомобилен йөртүче (МУП «Чиста шәһәр») – 1 кеше.
–экскаватор йөртүче (МУП «Чиста шәһәр») –1 кеше.
җиңел автомобиль (МУП «Чиста шәһәр») - 1 берәмл.
йөк автомобиле (МУП «Чиста шәһәр») – 1берәмл.

**Медицина һәм эпидемиология разведкасы төркеме**
(ш/с 4 кеше., 1 берәмл. техника):
– төркем командиры (табиб-инфекционист РҮХ) – 1 кеше.
– белгеч (СЭС) – 1 кеше.
– фельдшер (РҮХ) – 1 кеше.
– машина йөртүче (РҮХ) – 1 кеше.
җиңел автомобиль (РҮХ) – 1 берәмл.

**Дезинфекция төркеме**
(ш/с 5 кеше., 2 берәмл. техника):
– командир (РГВО табиб-эпизоотолог) – 1 кеше.
– фельдшер-лаборант (ветеринар РГВО) – 1 кеше.
– дезинфектор (РГВО) – 1 кеше.
– машина йөртүче-ветеринар (РГВО) – 2 кеше.
җиңел автомобиль – 1 ед.
дезинфекция җайланмасы ДУ-2 шасси ГАЗ-3309 (РГВО) – 1 берәмл.

**Үткәрү режимын тәэмин итүче төркем**
(ш/с 5 кеше., 2 берәмл. техника):
– тркем командиры (ЭЭМБ) – 1 кеше.
– регулировщик (ЭЭМБ) – 3 кеше.
– машина йөртүче-дезинфектор (РГВО) – 1 кеше.
патруль-пост хезмәте автомобиле– 1 берәмл.

**Җәмәгатьчелек тәртибен саклау төркеме**
(ш/с 6 кеше., 2 берәмл. техника):
– төркем командиры (ЭЭМБ) – 1 кеше.
– хезмәткәрләр (ЭЭМБ) – 5 кеше.
җиңел автомобиль (ЭЭМБ) – 2 берәмл.

**Санитар эшкәртү пункты**
(ш/с 5 кеше., 2 берәмл. техника):
– пункт командиры («Минзәлә районы Коммуналь челтәрләр» АҖ) – 1 кеше.
– дезинфектор («Минзәлә районы Коммуналь челтәрләр» АҖ) – 2 кеше.
– машина йөртүче (МУП «Чиста шәһәр») - 1 кеше.
– машина йөртүче («Минзәлә районы Коммуналь челтәрләр» АҖ) – 1 кеше.
автоцистерна (МУП «Чиста шәһәр») – 1 берәмл.

**Табиб-шәфкать туташы бригадасы**
(ш/с 4 кеше., 1 берәмл. техника):
– бригада командиры (РҮХ табибы) – 1 кеше.
– шәфкать туташы (РҮХ) – 2 кеше.
– машина йөртүче (РҮХ) – 1 кеше.
санитар автомобиль – 1берәмл.

**Янгын сүндерү расчеты**
(ш/с 1 кеше.,1 берәмл. техника):
– машина йөртүче-янгын сүндерүче (ДПК) – 1 кеше.
янгын сүндерү машинасы (ДПК) –1 берәмл.

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль районы
Башкарма комитетының карарына
Кушымта №3

дата __________ 20___ №______

**Отрядның сан составы**

| № п/п | Оешманың аталышы | Билгеләнә торган кешеләр саны, кеше | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1. | «Минзәлә район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 17 | Оештыру-штат структурасы нигезендә (Кушымта №2) |
| 2. | «Минзәлә район үзәк хастаханәсе» ДАССИ | 7 | |
| 3. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Минзәлә районы буенча бүлеге | 10 | |
| 4. | Минзәлә муниципаль районының Ирекле янгын сүндерү командасы | 1 | |
| 5. | "Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге" ФБССИнең Яр Чаллы шәһәрендә, Актаныш районындагы филиалы | 1 | |
| 6. | «Минзәлә районы Коммуналь челтәрләр» АЖ (санитар эшкәртү пункты) | 4 | |
| 7. | «Чиста шәһәр» МУП | 7 | |
| **Барлыгы:** | | **47** | |

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль районы
Башкарма комитетының карарына
Кушымта №4

дата __________ 20___ №______

**Отряд составына кертелгән**
**техника исемлеге**

| № п/п | Автомобиль һәм махсус техника тибы | Техника саны, берәмл. | Техника каян билгеләнә (оешманың аталышы) |
|---|---|---|---|
| 1. | Җиңел автомобиль | 4 | «Минзәлә район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ |
| | | 3 | Россия Эчке эшләр министрлыгының Минзәлә районы буенча бүлеге |
| | | 1 | «Чиста шәһәр» МУП |
| | | 2 | «Минзәлә район үзәк хастаханәсе» ДАССИ |
| 2. | Йөк автомобиле | 1 | «Чиста шәһәр» МУП |
| | | 1 | «Минзәлә районы Коммуналь челтәрләр» АҖ |
| 3. | Автоцистерна | 1 | «Чиста шәһәр» МУП |
| 4. | Экскаватор | 1 | «Чиста шәһәр» МУП |
| 5. | Янгын сүндерү машинасы | 1 | Минзәлә муниципаль районының ирекле янгын сүндерү командасы |
| 6. | ГАЗ-3309 шассидагы ДУ-2 дезинфекция җайланмасы | 1 | «Минзәлә район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ |
| | Күчмә дезинфекция җайланмасы | 1 | |
| **Барлыгы:** | | **17** | |

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль районы
Башкарма комитетының карарына
Кушымта №5

дата __________ 20___ №______

**Отрядны әзерлеккә китерү буенча “Минзәлә район дәүләт ветеринария берләшмәсе” ДБУ дежурныена Инструкция**

1.Отрядны әзерлеккә китерү Минзәлә муниципаль районының Гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе рәисе һәм аны алыштыручы затның карары белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.

2. “Минзәлә район дәүләт ветеринария берләшмәсе” ДБУ дежурные Отрядны әзерлеккә китерүгә команда (күрсәтмә) алу белән, алынган информация датасы һәм вакыты, мәгълүмат тапшыручының шәхси мәгълүматларын (фамилиясе, исеме, атасының исеме), аның кыскача эчтәлеге, контакт телефон номерын журналда теркәргә һәм бу турыда кичекмәстән Отряд командирына хәбәр итәргә тиеш.

3. Отряд командиры хәбәр итүгә һәм Отрядның шәхси составын җыюга күрсәтмә бирә.

4. Дежурный беркетелгән хәбәр итү схемасы буенча шәхси составка хәбәр итүне гамәлгә ашыра.